МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.03.2018 Казан ш. № 02-38

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2015 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына кагылышлы өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләү турында күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2015 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына кагылышлы өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләү турында күрсәтмәләргә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.03.2016 ел, № 02-32, 29.06.2016 ел, № 02-73, 30.09.2016 ел, № 02-116, 27.12.2016 ел № 02-157, 29.12.2016 ел, № 02-159, 31.03.2017 ел, № 02-30, 30.06.2017 ел, № 02-64, 26.09.2017 ел, № 02-90, 21.12.2017 ел, № 02-129, 26.12.2017 ел № 02-133 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
28 март, 2018 ел,
№ 02-38 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2015 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына кагылышлы өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, анықлау һәм тәгаенләү турында күрсәтмәләргә кертелә торган үзгәрешләр

1. «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәтбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты чыгымнары исемлеге һәм аларны тиешле максатчан статьяларга кертү кагыйдәләре» 2 пунктында:

а) « 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы гражданнарын социаль яклау» дәүләт программасы» 2.3. пунктчасында:

в целевой статье «03 1 01 00000 «Гражданнарның аерым категорияләренә федераль һәм республика законнарында билгеләнгән социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» төп чарасы» максатчан статьясында:

түбәндәге эчтәлектәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 07710 Мәскәү өлкәсе Хөкүмәтенең резерв фонды хисабына, Мәскәү өлкәсе Раменское районында Ан-148 самолеты фаҗигагә юлыгу аркасында һәлак булган затның гаиләсе әгъзаларына бер тапкыр түләнелә торган матди ярдәм

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Мәскәү өлкәсе Раменское районында Ан-148 самолеты фаҗигагә юлыгу аркасында һәлак булган затның гаиләсе әгъзаларына бер тапкыр түләнелә торган матди ярдәм түләүгә Мәскәү өлкәсе бюджетыннан бюджетара трансфертлар хисабына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Мәскәү өлкәсе Хөкүмәтенең резерв фонды хисабына, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 49010 02 0000 151 коды буенча чагылдырыла.»;

«- 51350 «Ветераннар турында» 12 гыйнвар, 1995 ел, № 5-ФЗ һәм «Федераль бюджет средстволары хисабына, Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 24 ноябрь, 1995 ел, № 181-ФЗ федераль законнарында билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 51350 Федераль бюджет средстволары хисабына, «Ветераннар турында» 12 гыйнвар, 1995 ел, № 5-ФЗ Федераль законда билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын) үтәгәндә җәрәхәтләнү, контузияләнү яки имгәнү аркасында инвалидка әйләнгән сугыш хәрәкәтләре инвалидларын, шулай ук эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкару системасы органнарының хәрби хезмәткәрләрен һәм рядовой һәм җитәкчелек составына керүче затларны; хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын) үтәгәндә һәлак булган сугыш хәрәкәтләре инвалидарын һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, хәрби хезмәткәрләрнең, эчке эшләр органнарының рядовой һәм җитәкчелек составына керүче затларның, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкару системасы органнарының рядовой һәм җитәкчелек составына керүче затларның гаиләләре әгъзаларын, әсирлектә һәлак булган, сугыш хәрәкәтләре барган урында хәбәрсез югалган дип танылган хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре әгъзаларын торак белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан субвенцияләр хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Ветераннар турында» 12 гыйнвар, 1995 ел, № 5-ФЗ Федераль законда билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү вәкаләтләрен хәл кылуга бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 35135 00 0000 151 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 51760 Федераль бюджет средстволары хисабына, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 24 ноябрь,1995 ел, № 181-ФЗ Федераль законда билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын) үтәгәндә җәрәхәтләнү, контузияләнү яки имгәнү аркасында инвалидка әйләнгән сугыш хәрәкәтләре инвалидларын, шулай ук эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкару системасы органнарының хәрби хезмәткәрләрен һәм рядовой һәм җитәкчелек составына керүче затларны; хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын) үтәгәндә һәлак булган сугыш хәрәкәтләре инвалидарын һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, хәрби хезмәткәрләрнең, эчке эшләр органнарының рядовой һәм җитәкчелек составына керүче затларның, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкару системасы органнарының рядовой һәм җитәкчелек составына керүче затларның гаиләләре әгъзаларын, әсирлектә һәлак булган, сугыш хәрәкәтләре барган урында хәбәрсез югалган дип танылган хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре әгъзаларын; инвалидларны һәм инвалид балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан субвенцияләр хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 24 ноябрь, 1995 ел, № 181-ФЗ Федераль законда билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү вәкаләтләрен хәл

кылуга бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 35176 00 0000 151 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

«03 5 01 00000 «Гаиләләргә социаль ярдәм чаралары системасын үстерү» төп чарасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 55730 Федераль бюджет средстволары хисабына, беренче бала туугa (уллыкка (кызлыкка) алу) бәйле рәвештә айлык түләүне хәл итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча беренче бала тууга (уллыкка (кызлыкка) алу) бәйле рәвештә айлык түләүне хәл итүгә федераль бюджеттан субвенцияләр хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Беренче бала тууга (уллыкка (кызлыкка) алу) бәйле рәвештә айлык түләүне хәл итү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен үтәүгә бюджетларга субвенцияләр» 000 2 02 35573 00 0000 151 керемнәр төренең тиешле коды буенча чагылдырыла.»;

б) «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшәүчеләрне сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасы» 2.4. пунктчасында «04 К 00 00000 «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшәүчеләрне сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» кече программасы» максатчан статьясында «- R0210 «2015 – 2020 елларга «Торак» Федераль максатчан программасының «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларына этәргеч бирү» кече программасын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- R0210 Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларына этәргеч бирү буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларына этәргеч бирү буенча чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларына этәргеч бирү буенча чараларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25021 02 0000 151 коды буенча чагылдырыла.»;

в) «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» дәүләт программасы» 2.13. пунктчасында «13 6 01 00000 «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәрен үстерү» төп чарасы» максатчан статьясында:

«- 53900 Федераль бюджет средстволары хисабына, юл эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү» чыгымнар юнәлеше атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 53900 Федераль бюджет средстволары хисабына, «Имин һәм сыйфатлы юллар» өстенлекле проекты кысаларында юл эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү»;

түбәндәге чыгымнар юнәлешләрен өстәргә:

«- 53901 Федераль бюджет средстволары хисабына, Казан шәһәре агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыру

- 53902 Федераль бюджет средстволары хисабына, Чаллы шәһәре агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыру

- 63900 «Имин һәм сыйфатлы юллар» өстенлекле проекты кысаларында транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Имин һәм сыйфатлы юллар» өстенлекле проекты кысаларында транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла».

- 63901 Казан шәһәре агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыру

- 63902 Чаллы шәһәре агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыру»;

г) « 2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы» 2.14. пунктчасында:

«14 2 01 00000 «Сөтчелек юнәллешендәге терлекчекне үстерү» төп чарасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 65420 Сөтчелек юнәлешендәге терлекчелектә продукт бирүчәнлекне арттыруга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, сөтчелек юнәлешендәге терлекчелектә продукт бирүчәнлекне арттыруга субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«14 4 01 00000 «Кече хуҗалыкларга ярдәм итү» төп чарасы» максатчан статьясы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 4 01 00000 «Яңа эшли башлаган фермерларга ярдәм итү» төп чарасы;

«14 4 05 00000 «Авыл хуҗалыгы кооперативларына ярдәм итү» төп чарасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 63260 Куллану кооперациясе оешмаларына күчмә сәүдәне хәл кылу өчен махсус автотранспорт сатып алуга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, күчмә сәүдәне хәл кылу өчен махсус автотранспорт сатып алуга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә куллану кооперациясе оешмаларына субсидияләр бирүгә  Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«14 6 06 00000 «Агросәнәгать комплексы объектларын төзү һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарны компенсацияләү» төп чарасы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 65460 Сөтчелек комплексларын төзүгә проект-смета документларын проектлауга һәм дәүләт экспертизасы ясауга бәйле авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, сөтчелек комплексларын төзүгә проект-смета документларын проектлауга һәм дәүләт экспертизасы ясауга бәйле авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

д) « 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасы» 2.17. пунктчасында «18 0 03 00000 «Җирле бюджетлар белән бюджетара мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәсен арттыру» төп чарасы» максатчан статьясында «- 80060 Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр бирү» чыгымнар юнәлеше атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 80060 Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына,  шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр бирү»;

е) «2017 – 2018 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Татарстан Республикасына ихтыярый күченүенә ярдәм итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» $2.29^3$. пунктчасында «34 0 01 00000 «Чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Татарстан Республикасына ихтыярый күченүе хисабына Татарстан Республикасының социаль-икътисадый һәм демографик үсешенә ярдәм итү» максатчан статьясы текстын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлешләре буенча төп чараны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 15700 Чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Татарстан Республикасына ихтыярый күченүенә ярдәм итү буенча чаралар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Татарстан Республикасына ихтыярый күченүенә ярдәм итү буенча чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- R0860 Чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Россия Федерациясенә ихтыярый күченүенә ярдәм итү буенча финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Россия Федерациясенә ихтыярый күченүенә ярдәм итү буенча чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Россия Федерациясенә ихтыярый күченүенә ярдәм итү буенча дәүләт программасына кертелгән төбәк күчеҥү программасында күздә тотылган чараларны тормышка ашыруга бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25086 00 0000 151 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

ж) «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Россия Федерациясе дәүләт бюджеттан тыш фондлары чыгымнарының программага кертелмәгән юнәлешләре» 2.30.пунктчасында «99 0 00 00000 Чыгымнарның программага кертелмәгән юнәлешләре» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- R0860 Чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Россия Федерациясенә ихтыярый күченүенә ярдәм итү буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Россия Федерациясенә ихтыярый күченүенә ярдәм итү буенча чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Россия Федерациясенә ихтыярый күченүенә ярдәм итү буенча дәүләт программасына кертелгән төбәк күченү программасында күздә тотылган чараларны тормышка ашыруга бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25086 00 0000 151 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.».

2. 2 нче кушымтада:

а) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «03 1 01 05860 | «Татарстан Республикасында яшәүчеләрне адреслы социаль яклау турында» 8 декабрь, 2004 ел, № 63-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының $8^2$ статьясында билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «03 1 01 07710 | Мәскәү өлкәсе Хөкүмәтенең резерв фонды хисабына, Мәскәү өлкәсе Раменское районында Ан-148 самолеты фаҗигагә юлыгу аркасында һәлак булган затның гаиләсе әгъзаларына бер тапкыр түләнелә торган матди ярдәм»; |

б) юлны

| | |
|---|---|
| «03 1 01 51350 | Федераль бюджет средстволары хисабына, «Ветераннар турында» 12 гыйнвар, 1995 ел, № 5-ФЗ һәм Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 24 ноябрь, 1995 ел, № 181-ФЗ федераль законнарында билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «03 1 01 51350 | Федераль бюджет средстволары хисабына, «Ветераннар турында» 12 гыйнвар, 1995 ел, № 5-ФЗ Федераль законда билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү»; |

в) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «03 1 01 51370 | Федераль бюджет средстволары хисабына, радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга аерым социаль ярдәм чараларын күрсәтү» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «03 1 01 51760 | Федераль бюджет средстволары хисабына, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 24 ноябрь, 1995 ел, № 181-ФЗ Федераль законда билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү»; |

г) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «03 5 01 53807 | Билгеләнгән тәртиптә оешма бетерелүгә, физик затлар эшчәнлеген (вәкаләтләрен) туктатуга бәйле рәвештә эшеннән җибәрелгән хатын-кызларга йөклелек һәм бала тудыру буенча пособиеләр түләү» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «03 5 01 55730 | Федераль бюджет средстволары хисабына, беренче бала туугa (уллыкка (кызлыкка) алу) бәйле рәвештә айлык түләүне хәл итү»; |

д) юлны

| | |
|---|---|
| «04 К 00 R0210 | «2015–2020 елларга «Торак» Федераль максатчан программасының «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларына этәргеч бирү» кече программасын тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «04 К 00 R0210 | Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларына этәргеч бирү буенча чараларны тормышка ашыруга финанслашыла торган чыгымнар»; |

е) юлны

| | |
|---|---|
| «13 6 01 53900 | Федераль бюджет средстволары хисабына, юл эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «13 6 01 53900 | Федераль бюджет средстволары хисабына, «Имин һәм сыйфатлы юллар» өстенлекле проекты кысаларында юл эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү» |

һәм шуннан соң түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «13 6 01 53901 | Федераль бюджет средстволары хисабына, Казан шәһәре агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыру |
| 13 6 01 53902 | Федераль бюджет средстволары хисабына, Чаллы шәһәре агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыру |
| 13 6 01 63900 | «Имин һәм сыйфатлы юллар» өстенлекле проекты кысаларында транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыру |
| 13 6 01 63901 | Казан шәһәре агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыру |
| 13 6 01 63902 | Чаллы шәһәре агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын тормышка ашыру»; |

ж) юлдан соң

«14 2 01 60430 Сатылган һәм (яки) төяп җибәрелгән үзе эшкәрткән сөтнең бер килограммына субсидияләр»

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:
«14 2 01 65420 Сөтчелек юнәлешендә продукт бирүчәнлекне арттыруга субсидияләр»;

з) юлны
«14 4 01 00000 «Кече хуҗалыкларга ярдәм итү» төп чарасы»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«14 4 01 00000 Яңа эшли башлаган фермерларга ярдәм итү» төп чарасы»;

и) юлдан соң
«14 4 05 63240 Авыл хуҗалыгы әзерләү-куллану кооперативларының, әзерләү оешмалары һәм куллану кооперациясе предприятиеләренең ит, йон һәм тире чималын сатып алу, эшкәртү һәм сату буенча чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр»

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:
«14 4 05 63260 Куллану кооперациясе оешмаларына күчмә сәүдәне хәл кылу өчен махсус автотранспорт сатып алуга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидияләр»;

к) юлдан соң
«14 6 06 65450 Агросәнәгать объектларын булдыру һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга, шулай ук техника һәм җиһазлар сатып алуга субсидияләр»

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:
«14 6 06 65460 Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең сөтчелек комплексларын төзүне проектлауга һәм проект-смета документларына дәүләт экспертизасы үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр»;

л) юлны
«18 0 03 80060 Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр бирү»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «18 0 03 80060 | Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр бирү»; |

м) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «34 0 01 15700 | Чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Татарстан Республикасына ихтыярый күченүенә ярдәм итү буенча чаралар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «34 0 01 R0860 | Чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Россия Федерациясенә ихтыярый күченүенә ярдәм итү буенча финанслашыла торган чаралар»; |

н) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «99 0 00 93990 | Хуҗалык хезмәте күрсәтү белән тәэмин итүче учреждениеләр» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «99 0 00 R0860 | Чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның Россия Федерациясенә ихтыярый күченүенә ярдәм итү буенча финанслашыла торган чаралар». |